Республика Татарстан
Кукморский Муниципальный район
СОВЕТ КОШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
КУКШЕЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422115, Республика Татарстан, Кукморский район,
с. Кошкино, ул. Театральная, д.38
тел.: (84364) 31-2-35
эл. почта: Kosh.Kuk@tatar.ru

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Кукшел авыл җирлеге Советы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2023 елның 21 сентябрендәге** **№20**

Кукмара муниципаль районы Кукшел авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 38 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукшел авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукшел авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Кукмара муниципаль районы Кукшел авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукшел авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 38 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукшел авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукшел авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәгә (2015 елның 15 июнендәге №31, 2021 елның 11 июнендәге №10, 2022 елның 15

июнендәге №11 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

16 нчы пунктның икенче абзацында «яисә алар тарафыннан тулы булмаган яисә дөрес булмаган мәгълүматлар бирү» дигән сүзләрне «үз чыгымнары турында белешмәләрне, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган мәгълүматлар бирү, яисә белә торып дөрес булмаган мәгълүматлар бирү» дигән сүзләр белән алыштырырга, «яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматны тапшырмау яки белә торып тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүмат тапшыру» сүзләрен «яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүмат тапшырмау, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белә торып тулы булмаган мәгълүматлар бирү яки белә торып дөрес булмаган мәгълүматлар бирү» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә hhth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә hhth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукшел территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Кукшел авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Хәмидуллин